СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д. 13, д.Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яшьләр урамы, 13 йорты, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366)53-4-32, факс (84366)53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**
**Урта Курса авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«18» декабрь 2025ел»** **№ 9**

**Урта Курса авыл җирлеге Советының “Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында” 2025 елның 30 апрелендәге 109 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында” 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында” 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында” 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы түләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында” 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында” 2025 елның 6 сентябрендәге 669 номерлы карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге Уставы нигезендә, Урта Курса авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Урта Курса авыл җирлеге Советының “Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү күләмнәре һәм шартлары турында”

2025 елның 30 апредендәге 109 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәтенә түләү турындагы Нигезләмәнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затның хезмәте өчен түләү акчалата бүләкләү рәвешендә башкарыла.

| Вазыйфа исеме | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге башлыгы | 23 201 |

2) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтне биләүче затларга хезмәт өчен түләү турындагы нигезләмәнең 3 пунктында (2 нче кушымта) “15 389 сум” сүзләрен “16 928 сум” сүзләренә алмаштырырга.

3) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагыла торган Нигезләмәнең 3 пунктын (3 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең айлык тариф ставкалары күләмнәре түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Бердәм тариф челтәренә түләү разрядлары | Тарифлы коэффициентлар | Тариф ставкалары (окладлар), сумнар |
|---|---|---|
| 1 | 1,0000 | 25 650,0 |
| 2 | 1,0113 | 25 940,0 |
| 3 | 1,0234 | 26 250,0 |
| 4 | 1,0347 | 26 540,0 |
| 5 | 1,0476 | 26 871,0 |

4) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге баш бухгалтерының хезмәт өчен түләүне оештыру һәм аның шартлары турындагы нигезләмәнең 3 пунктын (4 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Баш бухгалтерның вазыйфаи окладьі түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазыйфа | Халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары |
|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше |
| Баш бухгалтер | 31 000 сум |

2. Әлеге карарның 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керүен билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина

СОВЕТ СРЕДНЕКОРСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609003070